ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешнең 10 пунктына “урман янгыннарын сүндерүне” сүзләреннән соң “, моңа урман янгыннарын җәелдермәү һәм сүндерү максатларында шартлату эшләре башкару, урман янгыннарын сүндерү максатларында ясалма рәвештә явым-төшемнәр хасил итү гамәлләре үткәрү керми” сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) урманнарны саклау турында гражданнар, юридик затлар тарафыннан тапшырылган хисапларны карау;”;

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

“$6^1$) урманнарны яклау турында гражданнар, юридик затлар тарафыннан тапшырылган хисапларны карау;”;

түбәндәге эчтәлекле $13^6$ пункт өстәргә:

“$13^6$) урман патологиясен тикшерү нәтиҗәләре буенча урман патологиясен тикшерү актын раслау, аны вәкаләтле органның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына җибәрү;”;

2) 5 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 4 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты һәм 2 статьясы 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 19 ноябре
№ 89-ТРЗ